Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Юлсубино авыл җирлеге составына керүче Ямаш авылы торак пунктында
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2020 елның 19 ноябре № 2

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге составына керүче Ямаш авылы торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРӘ**:

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль Юлсубино авыл җирлеге составына керүче Ямаш авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән сайлау хокукына ия булган һәр кешесеннән, уку йортларына йөреп көндезге бүлектә укучы студентлардан гайре, 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.
2. Тупланган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтергә:

1. Зират янында контейнер мәйданчыгы төзү, контейнерлар сатып алу.
2. Контейнер мәйданчыгына юлга вак таш сатып алу.
3. Г. Тукай урамын яктыртуны реконструкцияләү
4. Өлешчә су белән тәэмин итү.
5. Кышкы чорда урамнарны кардан чистарту.
6. Музыка аппаратурасы сатып алу.
7.Янгын сүндерү өчен янгын колонкасы һәм янгын җиң сызганычлары сатып алу

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль Юлсубино авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Юлсубино авылы, Татарстан урамы, 56а йорт; Ямаш авылы,Х.Такташ урамы, 3в йорт; һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Юлсубино авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Гатиятов